**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 11 декабрендәге 5126 номерлы карары**

# Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 4 декабрендәге 4267 номерлы «2016-2025 елларга Казан шәһәрендә хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау программасы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2016-2025 елларга Казан шәһәрендә хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау буенча муниципаль программа чараларын төгәлләштерү максатыннан (алга таба – Программа) **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 4 декабрендәге 4267 номерлы «2016-2025 елларга Казан шәһәрендә хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау Программасы турында»гы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 28 декабрендәге 4571 номерлы, 2016 елның 29 апрелендәге 1873 номерлы, 2016 елның 29 июлендәге 2995 номерлы, 2017 елның 31 мартындагы 947 номерлы, 2018 елның 25 апрелендәге 1596 номерлы, 2019 елның 18 гыйнварындагы 159 номерлы, 2019 елның 11 ноябрендәге 3988 номерлы, 2020 елның 26 ноябрендәге 3466 номерлы, 2021 елның 30 июнендәге 1585 номерлы, 2023 елның 1 августындагы 2177 номерлы, 2024 елның 16 апрелендәге 1570 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Программаның 1 номерлы кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Төп чаралар исемнәре» графасындагы 1.11 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.11. Гражданнарны һәм хокук саклау органнары хезмәткәрләрен җәмәгать тәртибен саклауны һәм хокук бозуларны профилактикалауны тәэмин итүдә актив катнашканы һәм шәхси өлеш керткәне өчен бүләкләү»;

1.2. 3.4 пунктын 3.3 пункт дип санарга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**